ДУСЛЫК УЕННАРЫ
Муллалар һәм атакайлар бозга чыкты
> 2

РҮЗӘЛ МИНҺАҖЕВ:
«Тормышка башкача карый башладым»
> 3

АРАБЫЗДАН БЕРЕБЕЗ
Людмила Нигъмәтуллинага хезмәттәшләре дә, укучылары да гаҗәпләнә һәм соклана
> 3

БЕРГӘ ҖЫЕЛГАНДА
Балалар һәм әти-әниләр өчен махсус сәхифә
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 17 (28984) | Шимбә | 4 февраль | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Эльвира ВӘЛИЕВА

ЮЛГА БИРСӘҢ ЧЫН КҮҢЕЛ

224 миллиард сум! Татарстанга юл эшләренә әнә шул кадәр акча бүлеп биреләчәк. Республика юлчыларыннан да сөенечле хәбәр бар. «М12» югары тизлекле юлының Татарстандагы өлешен быел ук төзеп бетерәчәкләр. Башкалада Татарстан Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының еллык коллегиясе узды.

«Татар-информ»

«Казан Экспо»да үткән утырышта Россия Хөкүмәте Рәисе урынбасары Марат Хөснуллин, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та катнашты. Коллегиягә кадәр шул ук бинада Марат Хөснуллин катнашында Татарстанда юл эшләренең бишьеллык планын тормышка ашыруга багышланган киңәшмә дә узды. Ул ябык ишекләр артында үтте. Чара алдан фаразлаганнан озаккарак сузылганга күрә, коллегиянең эш тәртибенә дә үзгәрешләр кертергә туры килде хәтта. Сөйләшү бик җитди булган, ахры. «Хәлиткеч киңәшмә!» – дип бәяләде аны соңрак Татарстан транспорт һәм юл хуҗалыгы министры Фәрит Хәнифов.

Ел нәтиҗәләренә әйләнеп кайтыйк. Марат Хөснуллин республика юлчыларын сөендерде.

– Юл төзелеше күләме буенча Татарстанга тиңнәр юк. Мәскәүне исәпкә алмаганда, әлбәттә. Сезне әнә шундый зур күрсәткечкә ирешүегез белән котлыйм, – диде Россия вице-премьеры.

Аның сүзләренә караганда, былтыр ил күләмендә юл эшләренең бишьеллык планы расланган. Аның буенча Татарстанга 2028 елга кадәр ил казнасыннан 224 миллиард сум акча бүлеп биреләчәк. Уйлаган барлык эшләрне дә тормышка ашырсалар, биш елдан Татарстанда яңа юлларның гомуми озынлыгы 520 чакрым тәшкил итәчәк, дип фаразлана. Хәер, Марат Хөснуллин республика юлчыларына ышана.

– Татарстан – федераль, төбәк һәм муниципаль юллар төзегәндә бер чакрым төзелешнең бәясе, аны кулланышка тапшыру вакыты кебек күрсәткечләр буенча бердәм эш алып баручы беренче төбәк. Республика тәҗрибәсе илнең башка төбәкләре өчен дә файдалы. Шуңа күрә республикада бу юнәлештә укыту эшләрен оештырырга тәкъдим итәм, – дип, якташларын тагын да үсендерде ул.

Гаҗәп тә түгел. Республика юлчыларының эше – күз алдында. Татарстанда «М12» югары тизлекле автомобиль юлы төзелеше дәвам итә. Коллегия утырышында аны бу елның декабрендә үк төзеп бетерергә вәгъдә иттеләр. Былтыр әлеге төзелеш кысасында Татарстанга 101 миллиард сум акча бүлеп бирелде. Быел исә 96 миллиард сумлык эш башкарылачак.

– Күз алдына гына китерегез: Казаннан Мәскәүгә барып кайту өчен алты сәгать ярым вакыт җитәчәк. Бу – тагын да зуррак мөмкинлекләр дигән сүз, – диде Рөстәм Миңнеханов.

> «М12» югары тизлекле автомобиль юлы республиканың Кайбыч, Апас, Югары Ослан, Кама Тамагы, Лаеш һәм Питрәч районнары аша уза. Республика аша узучы яңа юлның озынлыгы 142 чакрым тәшкил итәчәк.

Түбән Каманы һәм Чаллыны уратып узу юлын да зур түземсезлек белән көтәләр. 81 чакрымлык яңа юлның бәясе 79 миллиард сум тәшкил итәчәк, дип фаразлана. Президент әйтүенчә, бу юл Кама сәнәгать кластерын тагын да үстерергә булышачак.

Россия Хөкүмәте Рәисе урынбасары эштәге кимчелекләргә дә төртеп күрсәтте. Ул Түбән Кама районы башлыгы Рамил Муллинны шелтәләде. Эш шунда ки, Рамил Муллин районда юлларга бәйле вазгыять турында чыгыш ясады.

– Түбән Камада машиналар саны артканнан-арта. 2018 елда шәһәрдә автомобильләр саны 91 меңне тәшкил итсә, былтыр әлеге сан 120 меңгә җитте. Шәһәрдә яшәүче һәр икенче кешенең диярлек «тимер ат»ы бар, – диде район җитәкчесе.

Марат Хөснуллин аннан шәһәрдә машина кую урыны белән тәэмин итү күрсәткече турында кызыксынды.

– Хәзер ул 0,8не тәшкил итә. Ә яңа торак төзегәндә машина кую урыны белән тәэмин итү күрсәткечен 1,2дән ким итмәскә кушабыз. Сүз күпкатлы паркинглар яки тигез мәйданнар турында бара, – дип ачыклык кертте Рамил Муллин.

– Мин сезнең белән бөтенләй дә килешмим, – диде Россия вице-премьеры. – Без фатир саен машина кую урыны төзергә ул дәрәҗәдә бай ил түгел. Дөньяда беркем дә болай эшләми. Бигрәк тә күпкатлы йортларда. Күпме генә машина кую урыны төзергә тырышсагыз да, сез барыбер автомобиль сатып алучылар артыннан куып тота алмаячаксыз. Мин бу хакта ике ел элек үк әйттем. Ышаныгыз: бу мәсьәләне ун еллап өйрәндем. Менә Казанда, мин әйткәннән соң, машина кую урыны белән тәэмин итү күрсәткечен бераз киметтеләр. Тик барыбер ул кадәр үк түгел әле. Ә сез аны тагын да арттырмакчы. Шәһәрдә бу кадәр урын һәм акча кайдан алмакчы буласыз? Димәк, йөрергә юл калмаячак. Мин Түбән Каманы бик яратам. Әмма шәһәр мэры белән килешмим. Мәсьәләгә карашыгызны үзгәртмәсәгез, калган бөтен гомерегезне «бөке»ләрдә утырачаксыз. Бу хакта яңадан уйларга киңәш итәм.

Марат Хөснуллин фикере белән Рөстәм Миңнеханов та килеште. Республика җитәкчесе сүзләренә караганда, юлларны бушатуның иң үтемле юлы – ул да булса, җәмәгать транспортын үстерү. Президент бу хакта сөйләгәндә, залда утыручы абзыйлар бер-берсенә карашып елмаеп куйды. Рульдә йөрергә күнеккән кешенең автобуска күчеп утырачагы бик шикле шул. Җитмәсә, анысы да иске. Фәрит Хәнифов сүзләренә караганда, республикада биш «яшь»тән өлкәнрәк автобуслар 70 процентка тузган әнә.

Президент әйтүенчә, юл-транспорт инфраструктурасын яңарту – Татарстанның тотрыклы үсешен тәэмин итүче юнәлешләрнең берсе. «Республикада яшәүчеләрнең һәм килгән кунакларның юллардагы иминлеге, аларга уңайлы шартлар тудыру, йөкләрне вакытында алып барып җиткерү юлларның сыйфатына бәйле», – диде Рөстәм Миңнеханов. Башкарылган эш күп, алда исә тагын да зуррак бурычлар көтә. Эшнең бер юнәлеше билгеле дә инде. Коллегия кысасында, Татарстан һәм «Россия тимер юллары» ААҖ арасында хезмәттәшлек турында килешү имзаладылар. Документка Рөстәм Миңнеханов һәм «Россия тимер юллары» җитәкчесе Сергей Дорофеевский кул куйды.

Яңа кагыйдә гамәлдә

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов республика Гаилә кодексына һәм «Мәгариф турында» законга үзгәрешләр кертү хакында законга кул куйган. Тиешле документ республика Президенты сайтына урнаштырылган.

Үзгәрешләр уллыкка (кызлыкка) алынган, гаиләгә сыендырылган балаларны (приемные дети) мәктәпкә кабул итүнең яңа кагыйдәләрен раслый. Алар бертуган (яисә бертуган булмаган) абыйсы-энесе, апасы-сеңлесе укый торган мәктәпләрдә белем алуга өстенлекле хокукка ия була. Мәгариф оешмасына конкурс буенча кабул итү яки индивидуаль сайлап алу очрагына гына бу кагыйдә кагылмый.

Документ алу җиңеләйгән

Татарстанның Күпфункцияле үзәк (МФЦ) офисларында күрсәтелүче хезмәтләр саны, узган елда 35кә артып, 287гә җиткән. Социаль әһәмиятле хезмәтләр алу мөмкинлеге арткан, кайбер документлар, шул исәптән паспорт, машина йөртү таныклыкларын рәсмиләштерү вакыты кимегән. Күпфункцияле үзәк директоры Ленара Мозаффарова әйтүенчә, социаль әһәмиятле хезмәтләр халыкка өзлексез күрсәтелә. Әйтик, МФЦ офислары узган елның Май бәйрәмнәрендә 8–17 яшьлек балаларга пособие түләү буенча гаризаларны кабул иткәндә, ялсыз эшләгән. Бу пособие алырга тиешле барлык гаиләләргә үзләренә уңайлы вакытта чиратсыз мөрәҗәгать итү мөмкинлеге биргән.

2022 елның 1 июленнән кайбер мөһим документларны алу гадиләштерелгән. Әйтик, хәзер Эчке эшләр министрлыгы бүлекчәләре Россия паспортын миграция бүлегенә документлар тапшырылганнан соң 5 эш көне эчендә рәсмиләштерә. Элек моңа 10–30 көн вакыт кирәк булган. Ә машина йөртүче таныклыгын рәсмиләштерү вакыты 10 эш көненә калган (элек 15 көн булган).

Үзгәрешләргә әзер

Узган елда Татарстанның җиңел сәнәгате чама белән 8 миллиард сумлык продукция җитештергән. Сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары Иван Колчин әйтүенчә, барлыгы якынча 3 миллиард сумлык текстиль әйберләр, 4 миллиард сумлык кием-салым, 1 миллиард сумлык күн әйберләр эшләп чыгарылган һәм сатуга озатылган. Гомумән алганда, 2022 елда җиңел сәнәгать 5 процентка үскән.

Моннан тыш, министр урынбасары искәрткәнчә, узган елда кайбер предприятиеләр мобилизацияләнүчеләр өчен кирәк-ярак җитештерүгә күчкән. Аның фикеренчә, тармакның икътисад шартлары үзгәрүгә әзер булуы турында сөйли бу. «Татарстанның җиңел сәнәгате төп тармакларның берсе булып тора. Биредә үсү мөмкинлекләре бар. Үзебезнең табигый, шулай ук синтетик чимал базасын үстерергә кирәк», – ди Колчин.

Күбрәк белсеннәр

Татарстанда 4–15 февраль көннәрендә инде менә 11 нче тапкыр «Ак халатлы фәрештәләр» фестивале үткәрелә. Мәктәп укучылары өчен киң колачлы профориентация чарасы бу. Аны Казан дәүләт медицина университеты, Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгы, Роспотребнадзор идарәсе, «Таттехмедфарм» оешмасы үткәрә. Төп максаты – балаларны турыдан-туры булачак эш урынында медицина һөнәрләре белән таныштыру. Шулай итеп, алар киләчәктәге белгечлекләре турында күбрәк белә.

Фестиваль кысасында район хастаханәләрендә, шулай ук Казанның төп дәвалау, профилактика оешмаларында Ачык ишекләр көне, төрле кызыклы чаралар үткәрелә. Аларда 3,5 меңләп кеше катнаша. Алдагы еллар тәҗрибәсе укучыларга бу чараның бик кирәкле булуын күрсәтте.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Борчыган мәсьәлә

Үзеңә дә аң буласы

Узган ел Татарстанда 17049 кешедә яман шеш авыруы барлыгы ачыкланган. Бу, алдагы ел белән чагыштырганда, 341 очракка күбрәк. Шул ук вакытта республикада яман шешне 1–2 стадиядә үк ачыклау очраклары да 62,5 процентка кадәр арткан.

Хәзерге вакытта республикада яман шеш диагнозлы 115 мең кеше исәптә тора. Бу хакта журналистлар белән очрашуда Татарстанның штаттан тыш баш онкологы Эдуард Ногманов хәбәр итте.

Татарстанда яман шеш диагнозы куелганнан соң, ким дигәндә, 5–6 ел яшәүчеләр саны да арткан. 2009 елдан бирле республикада андыйлар саны 14 процентка арткан. Россиянең атказанган табибы, Идел буе федераль округының баш онкологы Рөстәм Хәсәнов сүзләренә караганда, әлеге яман чиргә каршы көрәштә ирешкән казанышлар буенча Татарстан Идел буе төбәкләре арасында беренче урында тора.

Чирнең башлангыч чорда ачыклану күрсәткече дә 60 процентка җиткән. Белгечләр моны пандемия чорыннан соң диспансеризация, профилактик тикшеренүләрнең кабат тулы куәткә эшли башлавына бәйләп аңлата. Яман чиргә каршы көрәштә заманча җиһаз, алдынгы технологияләр кулланылуның да өлеше зур.

Яман шеш диагнозы белән исәптә торучыларның яртысыннан артыгын (60 процент) хатын-кызлар тәшкил итә. Белгечләр моны ир-атларның кыска гомерле булуына бәйләп аңлата. Яман шеш күбрәк олы яшьтә пәйда була. Ир-атларның күбесе исә аңа кадәр яшәргә өлгерми.

Республика онкология диспансерының баш табибы Илгиз Һидиятов сүзләренә караганда, яман шеш яшәрә дигән сүзләр дә дөреслеккә туры килми. «Чынлыкта ул картая гына бара. Ник дигәндә, гомер озынлыгы арта. Халык картая барган саен, яман шеш тә картая бара», – ди белгеч.

Республика халкы арасында иң еш очраган яман шеш төрләре арасында беренче өчлекне тире (14,2 процент), күкрәк (12,8 процент), эчәклек яман шеше (12,7 процент) алып тора. Тире яман шеше (меланома) очракларын кисәтү һәм вакытында ачыклау өчен, быел республикада «Миң турында» дип исемләнгән проект эшләячәк. Анда катнашу өчен иң элек телефонга махсус кушымта йөкләтергә кирәк.

Татарстанның штаттан тыш баш онкологы сүзләренә караганда, бу кушымта инде күптән эшли. Әмма быел ул республика халкына җәйләштерылачак.

– Чир раслана калса, әлеге кушымта аша турыдан-туры яшәү урыны буенча табибка да язылып булачак. Телефонга махсус кушымта йөкләткәч, иң элек махсус анкета тутырып, тәндәге миң, пигмент тап турында тулы мәгълүмат калдырырга кирәк. Аннары аны фотога төшереп, кушымтадагы махсус бүлеккә урнаштырырга туры киләчәк. Әгәр программа әлеге миң яки пигмент тапны шикле дип тапса, алга таба бу фотоны ике онкодерматолог тикшерәчәк. Шикләр расланган очракта, кешегә табибка күренергә кирәклеге турында смс хәбәр җибәреләчәк, – дип сөйләде Эдуард Ногманов.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

er-gosduma.ru

Михаил МИШУСТИН, Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе:

Россия – интернеты булган гражданнар саны буенча Европада беренче урында. Узган ел нәтиҗәләрен алсак, өйгә тоташтырылган һәм мобиль интернеттан файдалану буенча без – дөньяда алтынчы урында. Тулаем алганда, Көнбатышның тискәре мөнәсәбәтенә карамастан, дөньяда Россиянең цифрлаштыру өлкәсендәге уңышларын таныйлар.

(Digital Almaty форумының пленар утырышыннан)

РОССИЯДӘ – АВТОМОБИЛЬ БАЗАРЫ

Автостат мәгълүматларына таянып, Россиядә җиңел машиналар сату буенча вазгыятьнең ничек үзгәргәнен чамалап була.

2021 ел >> **1,5 млн** / 2022 ел >> **0,6 млн** берәмлек

Иң күп сатылган маркалар

- Lada – **175 мең** берәмлек
- Kia – **66 мең** берәмлек
- Hyundai – **54 мең** берәмлек
- Renault – **41 мең** берәмлек
- Chery – **39 мең** берәмлек

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Кичектерелгән «оҗмах»

Постиндустриаль җәмгыять. Без аны теләдек, телибез. Тик аның өчен икътисад белән сәнәгать һәрдаим көн кадагында, беренче урында торырга тиештер. Ләкин без яшәгән илдә, тарафларда гел генә алай барып чыкмый. Хәтсез очракларда икътисадны сәясәт билгели. Сәясәт икътисадның да, аның белән бергә бар булган җитештерүнең дә структурасын, күләмен, юнәлешен үзгәртеп куйгалый. Андый хәлне без бүген дә күпмедер күзәтәбез: чикләүләр, махсус хәрби операция икътисадка үз төзәтмәләрен кертте һәм кертә. Без омтылган җәмгыять тагын көн кадагыннан төшә…

Җәмгыятьләрнең әле тагын җитештерү, ясауны, аңа бәйле һөнәр ияләрен беренче урынга куйган индустриаль дип аталганы да бар бит. Һөнәрчегә, чүлмәкчеме ул, арба тәгәрмәче ясаучы остамы, элек-электән хөрмәт, ихтирам белән караганнар. Әйберне җитештерү, булмаганны булдыруда осталык гына түгел, сәләт тә кирәк. Җитештерү, производство – катлаулы процесс. Ә әзерне сатучы, әвештәвеш китерүче, шуның белән акча эшләүчене без әле күптән түгел генә «спекулянт» дип атый идек. Чөнки өстәмә бәя куеп, товарны кулланучыга ирештерүче сатучыдан аермалы буларак, ясаучы – юкны бар итүче ул. Ул – иҗатчы.

Ләкин менә ни хикмәт, дөнья алга барган саен, һөнәрчеләргә, җитештерүдә эшләүчеләргә ихтыяҗ акрынлап кими. Дөньяның алдынгы өлеше бүген артык михнәт күрми генә без әйткән, постиндустриаль дип аталган заманча тормышта яшәп ята. Постиндустриаль дөнья – нәрсә соң ул? Ул, беренчедән, барлык халыкның нибары 2–3 проценты илне авыл хуҗалыгы продукциясе белән тулысынча тәэмин итеп тора дигән сүз. Үз илен ашату гына җитмәгән, андыйлар хәтта икенче, өченче дөнья дип аталган тарафта яшәүче халыкның да өлешчә тамагын туйдыра. Икенчедән, постиндустриаль чор – җитештерүдә тир түккәннәр өлешенең дә 30–35 проценттан артмавы. Монысы без әйткән чорны билгеләүче төп фактор: теге яки бу ил, артык көчәнми генә, памперслардан, канцелярия скрепкаларыннан алып, катлаулыдан катлаулы станокларга, самолетларга кадәр барысын да ясап, булган ихтыяҗны канәгатьләндереп тора. Ул гынамы, үзеннән артканын кулыннан эш килмәгән чит-ятларга да сата.

Ә халыкның калган 60–65 проценты андый тарафларда ни майтара соң, диярсез. Постиндустриаль җәмгыятьнең асылын менә шул калганнар тәшкил итә дә инде: алар – куллану, хезмәт күрсәтү сферасында. Алар – чәчтарашханәләрдән башлап ресторан, туризм бизнесында, транспортта, сәүдәдә, сәламәтлек саклау, фән белән мәгарифкә кадәр булган бар өлкәләрдә. Алар – яшәешнең уңайлылыгын, сыйфатын, хәтта ки тәмен, рәхәтен тәэмин итеп торучылар, алга киткән фән һәм мәгариф дигәндә – киләчәген кайгыртучылар.

Табигый инде, постиндустриаль җәмгыятьнең асылын билгели торган мондый пропорцияләр тусын өчен, алдынгы технологияләр һәм шул технологияләр китергән югары хезмәт җитештерүчәнлеге булу фарыз. Башкача берни дә барып чыкмаячак. Әле тагын «кеше капиталы» дип аталучы капитал – гражданнарның гыйлемле, кайда эшләвенә карамастан, югары профессиональ әзерлекле, актив, булдыклы булуы да шарт. Биредә тагын шунысы да ачык: постиндустриаль фазага җитү, ирешү өчен, башта индустриаль стадияне аркылыга-буйга үтәргә – бар көчне җитештерүгә салырга, шул юнәлештә армый-талмый озак еллар эшләп, сыйфатлы һәм аз чыгымлы итеп һәммә нәрсәне ясарга өйрәнергә кирәк.

Җыеп әйткәндә, бар кирәк-ярак, җиһаз, азык-төлекне җитештерүдә хезмәткә яраклы халыкның өчтән береннән артыгы эшләми, ә дөньяң түгәрәк, тормыш сыйфаты югары икән – димәк, син алда иseме аталган шул җәмгыятьтә яшәп ятасың. Җитештерү яңа технологияләр сәбәпле шул дәрәҗәдә алга киткән, ул артык көч, чыгымнар сорамый. Чүлмәкне дә, арба тәгәрмәчен дә автоматик линияләр, роботлар ясый. Халык – технологияләр биреп торганны куллланучы гына. Без сөйләгән җәмгыять – кулланучылар, фән-техника китергәннең рәхәтен күрүчеләр җәмгыяте.

Россия дигәндә, без, 1990 нчы елларда «һава торышы»н билгеләгән кайбер икътисадчыларның рецептларына ышанып, индустриаль фазаны үтмичә генә постиндустриаль илләр арасына кереп китмәкче, үзенә күрә бер «ат йөреше» ясамакчы булган идек. Тик барып чыкмады. Нефть долларларына оҗмах сатып ала алмадык. Ул чакта да, соңрак та. 2000 нче елларга кергәч тә, үҗәтләнеп, акчаны Милли байлык фонды кебек олы янчыкларга җыйсак җыйдык, җитештерү өлкәсенә, технологияләргә юнәлтергә ашыкмадык. Киресенчә, «кара алтын» табуны арттырдык, чималчылыктан читләшмәдек. Ә бит нефть сәнәгате ул шундый әйбер: аны сәнәгать димәсәң, хәтере калыр. Аны «җитештерү» дип шартлы рәвештә генә атап буладыр. Чынлыкта ул Ходай җитештереп куйганны җир өстенә чыгару гына. Ул – промысел. Балык тоту, җәнлек аулаудан аерылса да.

Нефть долларларының янчыкка эләкмәгән өлешен туздыру, әрәм-шәрәм итүләргә карасаң, илгә тагын бер, аерым Хисап палатасы кирәк булмады микән, диясе килә. Чөнки акчаның югалыр юллары, тишекләре, акланмас чыгымнар җитәрлек булды – авызлыкланмаган коррупция, читкә капитал озатудан башлап, кеше башыннан санаганда, дөньяда иң зур чиновниклар армиясе, иң зур полициягә кадәр. Алардан да бигрәк, без сайлаган бик үк дөрес булмаган кыйбла – тышкы сәясәтнең эчкесеннән һәрчак өстенлеге. Анык, расланган икътисадый сәясәтнең юклыгы. Кая монда постиндустриягә урын? Нефть акчасына коендык, тик Гарәп Әмирлекләре була алмадык. Әле ул илне дә без сөйләгән җәмгыятькә шартлы рәвештә генә кертеп буладыр.

Җитештерү, индустриаль стадия, аңа битарафлыкта шуңа барып җиткән чаклар булды: без хәтта хәрби җиһазлар, техниканы (Россия Франциядән сатып алырга җыенган «Мистраль» хәрби корабларын искә төшерик), кайбер төр гади кораллар, шул ук электроника, оптик системаларны Көнбатыштан сатып алгаладык. Санкцияләр, әлбәттә, андый сәүдәгә чик куйды. Әмма факт факт булып кала. Җитештерүдә озак еллар тир түккән кеше буларак, ул өлкәгә булган игътибарсызлыкның гафу ителмәгәнлеген беләм. Төрле форс-мажор чыкканда бигрәк тә. Бүген без «бөек технологик держава» – Иранннан күпләп беспилотниклар сатып алабыз, баллистик ракеталар сорарга мәҗбүрбез. Постиндустриаль дәрәҗәгә ирешү өчен, индустриаль этапны үтү мәҗбүрилеген шушы хәлләр дә ачык күрсәтмиме?

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

ХОКУК ҺӘМ ДӨРЕСЛЕК САГЫНДА

Татарстанда 101 судья җитми. Республика судьялары киңәшмәсендә шул хакта хәбәр иттеләр. Судьялар узган елга хисап тотты. Чара Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашында узды.

2022 елның бер тармак өчен дә җиңелләрдән булмавы сер түгел. Республика Президенты әйтүенчә, былтыр хокук белән эш иткән органнарга да эш күп булды. Әйтик, хәрби комиссариат һәм чакырылыш комиссияләре эшчәнлеге белән бәйле эшләрне кыска вакыт эчендә карарга, гражданнарның хокукларын сакларга.

Рөстәм Миңнеханов, ришвәтчелеккә бәйле җинаятьләр саны да борчый, ди. «Гаепле кешеләр закон нигезендә җавап бирергә тиеш. Алар үз гамәлләре белән дәүләткә матди зыян гына салмый, абруен да киметә. Дәүләт органнары мондый хокук бозуларны бетерү өчен уртак көч куярга тиеш. Шул ук вакытта коррупция фактларын булдырмауның барлык алымнарын кулланырга кирәк», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Татарстан Президенты искәрткәнчә, 2014 елдан башлап республикада җәмәгать юстициясен үстерү максатларында махсус программалы юнәлеш кулланыла. Соңгы 3 елда Татарстан бюджетыннан дәүләт программасы чараларын гамәлгә ашыруга 1,8 млрд сумнан артык акча бүлеп бирелгән. Акча хезмәт хакы, ремонт, матди-техник тәэмин итү кебек сорауларны хәл итүгә тотыла.

Татарстан Югары Суды рәисе Илгиз Гыйләҗев хисабыннан аңлашылганча, былтыр судларда 1 млн 135 меңләп эш һәм материал каралган. Җинаять эшләренең 6 процентка кимүенә ирешелгән (114 меңгә калган). Ел дәвамында 14 мең кешене хөкем иткәннәр. Ә акланучылар күрсәткече – 5 мең кеше (20 процент).

Әмма кадрлар кытлыгы мәсьәләсе кала бирә. Рәис сүзләренчә, хәзер республикада 101 судья җитми.

Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, судлар каршында бик җитди бурычлар тора. «Мин ышанам: бердәм коллектив бу бурычларны уңышлы гына башкарып чыгар», – диде ул.

ДОГАЛЫ УЕН

Дин һәм милләтара дуслыкны ныгытабыз. Казанда хоккей буенча «Дуслык кубогы» III Бөтенроссия турниры ачылды. Анда илнең алты төбәгеннән 250 спортчы катнашачак.

Диннәр арасындагы дуслыкны ныгыту ниятеннән әлеге ярыш инде өченче тапкыр үткәрелә. Татарстан Премьер-министры Алексей Песошин билгеләп үткәнчә, күпмилләтле Казан Россиянең спорт тормышында әһәмиятле урын алып торуын берничә тапкыр раслады. Башкала даими рәвештә Бөтенроссия һәм халыкара спорт чараларын уздыру урынына әверелде.

– «Дуслык кубогы» турниры чын мәгънәсендә халык хоккей чемпионатына әверелде. Ул инде өченче тапкыр илебезнең төрле почмакларыннан үзешчән командаларны җыя. Катнашучы командалар безнең ике әйдәп баручы динне – православие һәм исламны тәкъдим итә. Күпмилләтле дөньяның нигезе һәм төп кыйммәте – халыклар арасындагы дуслык. Бу турнир исемендә дә чагыла, – диде ул турнирның ачылыш тантанасында.

Мөселманнарның һәм христианнарның бергәләшеп хоккей уйнау турниры дөньяның башка бер җирендә дә юк. Бу хакта тантанада каткат искәрттеләр. Алексей Песошин да көндәшлекне спорт мәйданчыкларында гына күрсәтәбез, ди.

– Бездәге халыкларның һәм диннәрнең тату яшәү традицияләре спортта дәвам итә. Тышкы көчләрнең безне аерырга тырышуына карамастан, без бердәмлекне саклыйбыз. Турнирның популярлыгы һәм тамашачыларның игътибары артыр, ә катнашучыларның географиясе киңәер, дип ышанам, – диде Хөкүмәт башлыгы.

Татарстан мөселманнарының Дини нәзарәте һәм Рус православие чиркәвенең Казан епархиясе оештырган быелгы турнирда Россиянең 6 төбәгеннән 10 команда уйнаячак. Ярышларда Казан, Санкт-Петербург, Кузнецк, Мордовия һәм Башкортстан командалары катнашачак. Уенчылар арасында хәзрәтләр, руханилар, хокук саклау органнары ветераннары, Татарстанның Югары Суды, Эчке эшләр министрлыгы һәм башка ведомстволар вәкилләре командалары бар. Шулай ук, быелгы турнирда беренче тапкыр хатынкызлар да алка сугачак. Турнир Казанның Спорт сараенда һәм «Баско» Боз сараенда уза.

Ләйсән САФИНА

Дуслар клубы

Илебезнең халыкара элемтәләрен ныгыту гына түгел, «Бердәм Россия» партиясенең дөньядагы абруен үстерүгә дә ярдәм итәргә тиешле «Россия дуслары клубы» оештырыла. Мәскәүдә «Бердәм Россия» партиясе Генераль советының Халыкара хезмәттәшлек һәм чит илләрдәге ватандашларыбызга ярдәм итү комиссиясе утырышында шул мәсьәлә каралды. Анда видеоэлемтә аша Татарстан Дәүләт Советы Рәисе, партиянең республикадагы бүлеге Секретаре Фәрит Мөхәммәтшин катнашты.

Комиссия җитәкчесе, Россия тышкы эшләр министры Сергей Лавров, утырышны ачып, партия комиссиясенең чит илләр белән хезмәттәшлекне киңәйтүдәге ролен билгеләп үтте. Ул Россиянең күп еллар дәвамында дөньядагы төрле халыкларга колониаль изүдән котылу өчен көрәшүгә ярдәм итеп килүен басым ясап әйтте. «БМО Генераль ассамблеясы 1960 елда нәкъ менә илебезнең тәкъдиме белән колониаль илләр һәм халыкларга бәйсезлек бирү турында декларация кабул итте. – Без үсеп килүче илләрнең колониаль изүдән коткаруны төгәлләү зарурилыгы турындагы таләбен хуплыйбыз».

Партия комиссиясе әгъзалары фикеренчә, илебездә булдырылучы «Россия дуслары клубы» бу эштә ярдәм итәргә тиеш. Комиссия әгъзалары әлеге тәкъдимне хуплап, аны тормышка ашыру мәсьәләләрен карады.

Фәрит Мөхәммәтшин үзенең чыгышында башлангычның бик вакытлы пәйда булуын билгеләп үтте. Аның әйтүенчә, Россиянең халыкара элемтәләрен ныгыту гына түгел, партиянең дөньядагы абруен үстерүгә дә хезмәт итәчәк бу. «Россия дуслары клубы»н булдырып, традицияләр һәм мәдәниятебезне белүче күп кенә чит илләр студентларының илебез вузларында укуын да исәпкә алырга кирәктер, мөгаен, – диде ул. – Май аенда Казанда ислам дөньясы илләре вәкилләре катнашында «KazanForum» XIV Халыкара икътисадый форумын үткәрү күздә тотыла. Ул Россия Президенты карары нигезендә федераль статус алды».

ҮЗЕҢӘ ДӘ АҢ БУЛАСЫ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Яшерен-батырын түгел, теләсә кайсы чирне соң чиккә җиткәч кенә дәваларга күнеккән без. Төрле сәбәпләр табып, табибка баруны кичектереп гомер уза. Белгечләр исә моны зур хата дип атый.

– Әгәр кеше үзе тикшеренергә килмәсә, табиб кына бернәрсә дә эшли алмаячак. Кеше еш кына чирнең үзен ниндидер билгеләр аша сиздерүен көтә. Әйе, тәндәге тапларны, үзгәрешләрне күреп була әле. Әмма шул ук күкрәктәге яман шешне гади күз белән күреп, кул белән капшап кына чамалап булмаска да мөмкин. Кеше үзе сизәр дәрәҗәгә җиткәндә, ул инде шактый азган була. Шуңа күрә маммография узарга кирәк. Эчәклектәге яман шеш тизәктәге яшерен кан анализы аша ачыклана, – ди Рөстәм Хәсәнов.

Колоноскопияне дә вакытында – өч елга бер тапкыр ясатырга киңәш итә табиблар. Эчәклектә үзгәрешләр булса, аны ел саен узу хәерле. Белгечләр бу процедурадан куркырга кирәкми, дип тә искәртә. Ник дигәндә, хәзер аны кешене 15 минутка йоклатып та ясыйлар. «Машинаны да гел карап, төзәткәләп торабыз. Сәламәтлек тә шул ук машина кебек. Аны да гел төзәткәләп, карап, тәрбияләп торырга кирәк», – ди Рөстәм Хәсәнов.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Рухи-әхлакый хәзинәләрне саклау һәм үстерүгә, тынычлыкны һәм конфессияара татулыкны ныгытуга зур өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары **Шәйхразиев** Васил Габделгаяз улы **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

* * *

Республикада тимер юл транспортын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Россия тимер юллары» ачык акционер җәмгыяте филиалы – Элемтә үзәк станциясенең структур бүлекчәсе – Түбән Новгород элемтә дирекциясе структур бүлекчәсе – Казан төбәк элемтә үзәге өлкән электромеханигы **Мартынов** Николай Михайлович, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыруга лаеклы өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлеге башлыгы **Михеев** Виктор Викторович, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, ветераннар хәрәкәтен үстерүгә зур өлеш кертүе һәм актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен Актаныш районының ветераннар (пенсионерлар) җирле иҗтимагый оешмасы башлангыч ветераннар оешмалары белән эшләү даими комиссиясе рәисе **Нурлыев** Нургаян Гаян улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

ҖИРГӘ ТАЯНГАН ЕГЫЛМЫЙ

Авыл тормышы

Тәтеш районына барырга җыенуымны әйткәч, Татарстанның крестьян-фермер хуҗалыклары берләшмәсе җитәкчесе Камияр Байтимеров: «Байраш авылында Рифхәт Заһидуллин исемендәге фермер хуҗалыгына да кереп чык әле. Эш нәтиҗәләре буенча алар – республикада бишенче урында», – дигән иде.

Тагын шунысын да белдем. Җиде ел элек башкаланың бер предприятиесендә әйдәп баручы инженер булып эшләгән Илмаз Заһидуллин әлеге фермер хуҗалыгына кайткан. Бүген үзе җитәкче булып эшли. Байраш олы юлдан Тәтеш ягына борылгач, дүртенче авыл икән.

Юл буенда кыска кунычлы киез итегенә галош кидергән (безнең якларда «чусинкә» дип йөртәләр), бер ир-атның кул изәвен күреп алдым. Юл буенда басып торучы хуҗалык җитәкчесе Илмаз Заһидуллин булып чыкты.

– Бигрәк матур инде безнең авыл, – диде ул елмаеп.

Тирә-якка күз салам. Чыннан да Байраш бик матур авыл икән. Әллә каян балкып торучы мәчете, мәктәбе, терлекчелек бинаалары, башка бик күп корылмалары, шәхси хуҗалыклары, терлек белән тулы ишегаллары авылда булдыклы, уңган кешеләр яшәвен дәлилли.

Фермер хуҗалыгының конторасындагы чисталык-пөхтәлеккә дә сокланырлык. Аяк киемнәренә кадәр, бусагадан керүгә салып, җиңелчә башмакка алыштырасы.

– Әти һәр җирдә тәртип булуын ярата иде. Утыз елга якын шушы фермер хуҗалыгында эшләде. Бу вакыт эчендә хуҗалыктагы эш күрсәткечләре бик күпкә артты. Эш шартлары яхшырды. Бездә эшләүчеләрнең уртача хезмәт хакы 38 мең 197 сумны тәшкил итә. Киләчәккә тагын да зуррак өметләр белән яшибез. Боларның барысы өчен дә авылыбыз халкы 30 ел элек Байрашка хуҗалык

җитәкчесе булып килгән Рифхәт Мостафа улына рәхмәтле, – ди Илмаз Заһидуллин.

Бүген фермер хуҗалыгы республикада иң нәтиҗәле эшләүчеләр рәтендә. Хуҗалыкның 3 мең гектардан артык сөрү җире, меңгә якын мөгезле эре терлеге, амбарлары тулы ашлыгы, башка төрле мал-мөлкәте бар. Кышлатуга бер баш терлеккә 34 центнер азык әзерләгәннәр. Бөртеклеләрдән гектарына 46 центнер, шикәр чөгендеренең гектарыннан 394 центнердан артык уңыш җыеп алганнар.

Рифхәт Заһидуллин Буа районы Суыксу авылында күпбалалы гаиләдә туып-үскән. Әтисе Мостафа балаларының һәркайсында хезмәтне ярату, җиргә тугрылык тәрбияләргә тырыша. Аның: «Җиргә таянсагыз, егылмассыз», – дигән сүзләре хәзер инде буыннан буынга күчә бугай.

Үзгәртеп кору елларында Байраш авылы җирләренә дә күз салучылар арта. Хуҗалык малларына кызыгучылар табылып тора. Әмма колхоз булып эшләгәндә дә, крестьян-фермер хуҗалыгы оештырылгач та, Рифхәт Заһидуллин бернинди янау-куркытуларга баш бирмичә, хуҗалыкның мал-мөлкәтен таратуга юл куймаска тырыша.

Бу еллар эчендә Байраш авылының хәле күзгә күренеп яхшыра. Хуҗалык ярдәме белән генә түгел, дәүләт программалары нигезендә дә биредә шактый эшләр башкарылган. Модульле ветеринария, фельдшер-акушерлык пункты, яшь гаиләләр өчен йортлар төзелгән.

Байраштан ерак түгел урнашкан Никифоровка авылы язмышына да битараф калмаганнар. Кайчандыр зур терлек фермасы булган авылны эшле итәр өчен, фермер хуҗалыгы биредә яңа ферма төзегән. Дәүләт программасы нигезендә бетон юл салынган. Хуҗалыкта механизаторлар өчен җылытылган ремонт мастерское сафка баскан. Күпфункцияле үзәк төзелү дә ямь өстенә ямь өстәп тора. Рифхәт Заһидуллинның алга куелган максатларга ирешү өчен никадәр зур тырышлык куеп эшләвен күргән авыл халкы аның һәр башлангычын хуплап каршы ала.

– Әти үрнәге минем һәр эшемдә ярдәм итә. Гаиләдә олы малай буларак, бала чактан ук колхозның төрле эшләрендә катнашырга тырыша идем. Җәй көннәрендә ярыша-ярыша чөгендер утадык. Берничә ел комбайнчы ярдәмчесе булып та эшләдем. Мәктәптә укыганда ук механизатор таныклыгы бирделәр. Казан авыл хуҗалыгы институтында яратып укыдым. Бер үк вакытта, әти киңәше буенча, читтән торып юрист белгечлеге дә алдым. Арча кызы Әлфия белән гаилә корып, ике бала үстерәбез. Шәһәрдә яшәсәк тә, авылга тартты. Дәү әти һәм әтинең: «Җиргә таянсаң, егылмассың», – дигәне гел исемдә булды. Җиде ел элек әтинең эшен дәвам иттерергә уйлап, авылга кайттым. Әти канаты астында җиңелрәк иде. Хәзергә кыен чаклар әле, – ди яңарак кына якын кешесен югалткан яшь фермер.

Камил СӘГЪДӘТШИН

РҮЗӘЛ МИНҺАҖЕВ: «БЕЗ БЕРДӘМ ХАЛЫК ИКӘН»

Ватан хакына

Ике арага күпер салучы, Мөслим районының Метрәй авылы егете Рүзәл Минһаҗев хәрби операциядәге якташ егетләребез янына алтынчы тапкыр барырга җыена. Ул Фирдүс Тямаев төркемендә эшли. Алар җырчы белән берлектә узган елның сентябрь аеннан бирле егетләргә гуманитар ярдәм илтеп тапшыра. Рүзәл мондагы сәламнәрне, күчтәнәчләрне ияләренә җиткерә. Сабыйлар да аның аша әтиләренә хат юллыйлар.

Рүзәл сөйләгәннәрне тыныч кына тыңлап булмый. Күңел тула. Ирексездән күзләрдән яшь тама. Беренчедән, олы йөрәкле кешеләргә сокланасың, икенчедән, туган яктан бер хәбәр булса да көтүче егетләрне уйлыйсың.

– Ай саен Фирдүс Тямаев төркеменнән өч егет махсус хәрби операция зонасында хезмәт итүче якташларыбызга ярдәм илтәбез. Мин, бу эштә катнашып, шуны аңладым: без – бердәм халык. Социаль челтәрләрдәге аккаунтларымда гел изге күңелле кешеләр генә икән. Бер белдерү куюым җитә – көн дәвамында кирәкле әйберләрне җыябыз да алабыз. Безнең егетләргә Башкортстанның төрле авылларында яшәүчеләр дә булыша. Үзләреннән зур өлеш кертүчеләр бик күп. Авылдашым Ленар Галәев күркә итеннән тушенкалар ясап бирде. 3 литрлы 20 банка бал бирүче кеше дә булды. Халык бик ярдәм итә, – ди ул.

Рүзәл әйтүенчә, егетләрне аерып тормыйлар. Юлларына кем очрый, алдан әзерләп куелган күчтәнәчләрне тапшырып баралар. Исемле посылкаларны иясенә тапшырырга тырышалар. Алар алгы сызыкта булсалар, командирларына калдырып китәләр икән.

– Андагы хәлләрне үзең күрмичә аңламыйсың. Мин егетләр белән бергә шунда кунып кайтам. Анда күзгә йокы керми. Тормыш кыйммәтләренә төшендерә торган җир ул. Анда шатлыкның ни икәнен чынлап аңлыйсың! Егетләрнең без алып килгән ярдәмгә ничек сөенгәннәрен күрсәгез иде! Алар үзләре әллә ни күп әйбер дә сорамый. Күреп кайткач, ниләр кирәген чамалап, үзебез алып барабыз, – ди Рүзәл. – Әле менә Азнакайда яшәүче алты яшьлек бер бала әтисенә хат җибәрде. Аны тапшырдым. Беләсезме, ул анда ни дип язган? «Әтием, бүген ике керфегем төште. Шуларны тотып, теләк теләдем. Берсен бу хатым әтиемә барып җитсен дип очырдым, икенчесен тотып, әтием яныма кайтсын дип теләдем», – дигән. Әлбәттә, мондый хатлар елата. Мин үзем дә егетләр янына баргач, яшьләремне тыя алмыйм. Менә кайда ул тормыш кадере! Аны аңлар өчен шунда ярты көн булуың да җитә.

Рүзәл андагы егетләрнең дуслыгына да шакката. Чын дуслык, ди ул аны. Алар бер-берсе өчен җанын бирергә риза булып торалар икән.

– Анда барасыбызны белүгә, егетләрнең якыннары килә. Әниләре, кысып-кысып кочаклагыз әле улымны, ди. Әманәтләрне үтим. Әниләренең җылысын бирә алмасам да, егетләрне кочаклыйм. Егетләр исә, якыннарын күреп сөйләшүемне үтенә. Күп сөйләшмиләр алар. «Җиңеп кайтабыз», – диләр. Бөтенесе дә бер теләк белән яши: исән-сау әйләнеп кайтсам, барлык туганнарымны кочаклап үбәр идем.

Рүзәл алтынчы сәфәренә дә әзер. Казанга килеп, кайбер кирәк-ярак аласы калган. Ул гади кешеләргә бик рәхмәтле. Ниләр генә китермиләр икән. Хәтта керләрен юдыртыр өчен кер юу өчен машиналарына кадәр алып килеп биргәннәр.

– Егетләргә шәхси гигиена, медицина кирәк-ярагы, җылы киемнәр кирәк. Шулай ук бензокискеч, изолон, монтаж күбеге (монтажная пена), балта, пычкы, мич, мунча ташы, бинокль, генератор, кечкенә газ баллоннары, йокы капчыклары, оекбашлар сорыйлар. Машина кирәген үзебез аңладык. Анысын сорамый алар. Без алып барабыз, – ди Рүзәл. – Иң авыры – аларны калдырып китү. Әйтерсең йөрәгең шунда кала. Мин 50 чакрым буе артыма карап барам. Без монда оҗмахта яшибез. Егетләр белән чагыштырып карыйм да, мин монда үземне бер файдасыз кешегә саныйм хәтта. Кайткач, төннәр буе йокламыйча ятам. Барысын да йөрәгем аша үткәрәм. Егетләр күз алдымнан китми.

Рүзәл үзләренә ярдәм иткән бар кешегә чиксез рәхмәтен җиткерә. «Без бердәм милләт, көчле халык икән», – ди ул. Егетләрне исә хәрби операция тукталганчы ташламаска сүз бирә.

Татарстан гуманитар юнәлештә шактый эш алып бара. Саннарга килсәк, Казаннан Лисичанск шәһәренә гуманитар ярдәмнең беренче партиясе 10 ноябрьдә китте. Икенче партия – 22 ноябрьдә, өченче һәм дүртенчесе 7 һәм 20 декабрьдә кузгалды. Яңа ел алдыннан җибәрелгән партиясе 12 тонна мандарин, балалар өчен 2 меңләп күчтәнәчтән тора иде. Луганск өлкәсенә барлыгы 32 фура җибәрелгән инде. Гуманитар йөкнең гомуми күләме 600 тоннадан артты. Казан шәһәрендә гуманитар ярдәм җыю пунктларының эш вакыты: эш көннәрендә – 9.00–18.00, шимбә – 9.00–14.00 сәгатьләрдә. Пунктларны табу җиңел – аларда «Игелекле Казан» логотибы сурәтләнгән.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Шәхес

БӘКЕГӘ ТӨШӘРГӘ ДӘ РИЗА

Чаллы шәһәренең 5 нче мәктәбендә инде 46 нчы ел рус теле һәм әдәбиятын укытучы (гомуми стажы – 52 ел) Людмила Нигъмәтуллинага хезмәттәшләре генә түгел, укучылары да гаҗәпләнәдер, мөгаен. Дөресрәге, сокланадыр. Физик яктан да, рухи яктан да ничек шулай яшь көе кала ала ул? Югыйсә, аз да түгел, күп тә түгел, 75 яшен тутырган бит.

Бозлы якшәмбе

Яшь кала алуын сер итеп сакламый Людмила Михайловна: иртә белән ярты сәгать тирәсе зарядка ясый, салкын су яки бәкедә коенып ала икән.

– Спорт белән Төрекмәнстанда, мәктәптә укыганда ук кызыксына башлаган идем, – дип сөйли ул. – Әти-әниемә рәхмәт, 7 нче сыйныфта җиңел атлетика буенча ярышларда алган беренче грамоталарымны саклаганнар. Хәзер алар, күңелне җылытып, архивымда ята. Соңрак спорт гимнастикасы белән кызыксынып киттем, җитдирәк шөгыльләнә башладым. Хәтта институтка кергәч тә, җиңүләр яулавымны дәвам иттердем әле. Ә менә бәкедә коена башлавым акыл иясе, искиткеч белгеч, Чаллы шәһәрендә төзелешне механикалаштыру идарәсе җитәкчесе Иван Мухрыгинга бәйле. 1988 елда ул «Исәнмесез» дигән клуб оештырды. Килешәсездер, исеме үк ничектер үзенә тартып тора. Сәламәт яшисе килгән һәркемгә килергә ярый иде анда. Күбәү идек без. Һәр якшәмбе Мәләкәс елгасы аша салынган күпердә очраштык. Анда төзелеш вагоны тора иде. Шунда киемнәребезне алмаштырабыз да балта белән бәке тишәбез. Колгалар белән боз кисәкләрен «куып җибәрәбез». Аннан баскычтан төшәбез дә рәхәтләнеп йөзәбез. Әлбәттә инде, моңа ияләшергә кирәк. Тиз генә йөзеп тә, бозлы суга чумып та булмый. Әмма бер гадәтләнгәч… Бу рәхәтлекне сөйләп тә, аңлатып та булмый. Урамда 20 градус салкын, ә син судан чыгасың да туңу турында уйлап та карамыйсың, киресенчә, эссе мичтән ургылган кебек, пар чыга, тән кызыша. Ә аннан соң вагонда самавырда кайнаган чәй эчә-эчә, ничек тукланырга, нинди физик күнекмәләр ясарга кирәклеген сөйләшәбез. Мондый якшәмбеләрне без олы бәйрәм кебек көтеп алдык.

Мондый рәхәтлекне озынайту өчен, якшәмбене генә көтеп тормадык, әлбәттә. Үзебез яшәгән ЗЯБ бистәсендә 5–6 кеше җыелдык та көн саен диярлек бәкегә чумып кайттык. Моның өчен иртәнге 5тә торырга кирәк иде, чөнки өйгә кайтып, чәчне киптереп, эшкә йөгерәсе бар бит әле.

Әйтергә кирәк, ул елларда мондый ысул белән сәламәтлеген ныгытучылар, чыныгырга теләүчеләр бик күп иде. Без хәтта төп состав белән Казанга, республика слетына да бардык. Бер слетны Мәләкәс ярындагы вагоныбыз янында да үткәрделәр.

Ни кызганыч, еллар узды, клуб акрынлап таркалды. Әмма шөгылемне ташламадым. Хәзер мин бәкедә коенырга ике дус хатын белән йөрим. Дөрес, олыгайган саен чамасын белергә тырышабыз. Шуңа күрә атнасына ике яки өч тапкыр гына чыгабыз. Салкынлык 20 градустан артса да, туктап торабыз.

Ышаныч

Людмила Михайловна яхшы укытучы буларак кына түгел, спортчы буларак та ышаныч яулый укучылары арасында. Бер чыгарылыш сыйныфы аның хәтеренә бигрәк тә нык уелып калган.

– Миңа ничектер гел яхшы әти-әниләр, тырыш укучылар туры килә, – ди ул. – Ул вакытта 5 нче сыйныфка яңа укучыларны кабул итеп алдым да чыныгу дәресләре үткәрергә булдым. Башта әти-әниләр белән җыелыш үткәрдем. Бәхетемә, арада Беккер фамилияле бер табиб та бар иде. Беренче минуттан ук минем яклы булып, бик нык ярдәм итте ул миңа. Аңа бүген дә рәхмәтлемен. Күз алдына китерегез әле: икенче сменаның бишенче дәресе бетүгә, малайлар чишенә-киенә торган урынга йөгерәләр, ә кызлар сыйныф бүлмәсендә калалар. Ник дисезме? Мәктәп киемнәрен салып, коену костюмнарын кияргә. Шуннан 32 чиләкне берьюлы күтәреп алалар да, мәктәп ишегалдына чыгып, түгәрәккә тезелешеп басалар, краннан агызган салкын суны өсләренә коялар. Бу бәкедә коеныр өчен әзерлек кенә иде әле. Ул елларда укучылар «Кама таңнары» газетасында «Яраткан укытучыбыз белән бәкегә дә төшәргә риза» дигән исем белән мәкалә дә бастырганнар иде. Фотолар да сакланган. Мин бу балаларым белән бүгенгәчә горурланам. Шундый режимда 4 ел, ягъни 9 нчы сыйныфка кадәр яшәдек әле без. Аннан аларны беренче сменага күчерделәр. Мәктәпне тәмамлаганчы, якшәмбе көннәрендә бәке янында гына очраштык.

Бүген укучыларны спортка җәлеп итү авыррак, әмма мөмкин хәл. Кызыксындыру чаралары бик күп бит. Аны партада да башларга була. Мәсәлән, контроль диктант язганда, 20 бүләккә ия йөзүче Шаварша Карапетян турында текст сайлап аласың. Спорт терминнарыннан гына торган сүзлек диктанты да файдалы булыр иде. Имтиханнарга әзерләнгәндә, «Сәламәт яшәү рәвеше – нәрсә ул?» дигән темага инша язып, шушы темага рәхәтләнеп әңгәмә корырга була. Андый үрнәкләр бар инде ул. Мәсәлән, Лев Толстой хикәясендә дә укучылар «Костылин ни өчен Жилиннан көчлерәк?» дигән сорауга җавап эзлиләр бит.

Шпагат

Людмила Михайловна җиңел генә шпагатка утыра. Бу гамәленә бәйле бер вакыйганы да кызык итеп сөйли ул.

– Бервакыт 10 нчы сыйныфка яңа укучы килде. Бик тәкәббер, беркем белән дә хисаплашмый, күрәсең, өйдә бик иркәләп кенә үстергәннәр. Үзе акыллы, рус теленнән дә яратып шөгыльләнә, ә менә әдәбиятны бар дип тә белми. Бу кирелеген, мин әдәбияттан барыбер имтихан бирмим бит, дип аңлата. Сөйләшергә бик авыр иде аның белән. Көннәрдән беркөнне дәрестә чираттагы «2ле»не куйдым да: «Әйт әле, син әдәбият белән шөгыльләнсен өчен мин нишли алам?» – дигән сорау бирдем. Ул миңа карап торды да, күзен дә йоммыйча: «Әгәр шушы яшегездә шпагатка утыра алсагыз, мин әдәбият белән шөгыльләнәчәкмен. Сезгә ике ай вакыт бирәм», – диде. Озак уйлап тормадым. Туфлиләремне салдым да такта янында, бөтен укучылар алдында шпагатка утырдым. Егетнең күзләре шар булды. Әйтергә кирәк, педагогика кысасына сыймаган мондый алымны мин бер генә тапкыр кулландым. Аның каравы файдасы тиде.

Дәрес кенә түгел

– Укытучы эше дәресләр үткәрү генә түгел бит ул. Укучылар белән мин Алабуга, Санкт-Петербург, Казан, Мәскәү, Менделеевск, Чистай, Псков, Киев, Уфа шәһәрләрендә булдым. Үз вакытында экскурсовод курсларын да тәмамлаган идем. Бик ярап куйды. Алабуга, Казан, Чаллы шәһәрләрендә экскурсияләрне әле дә үзем үткәрәм.

Укучылар белән яхшы мөнәсәбәтләр урнаштыру җиңел түгел. Моның өчен тәҗрибә, тырышлык кирәк. Бу җәһәттән мин әлегә кадәр иң беренче эш урынымдагы мәктәп директоры Владимир Аксеновны искә алам. Сугыш ветераны иде ул. Сентябрь буена һәр дәресемә диярлек кереп утырды, аннан шундый итеп кирәгемне бирде ки, өемә күз яшьләренә тыгылып, елый-елый кайтып киттем. Аның каравы дәресләрне ничек үткәрергә, балалар белән ничек аралашырга кирәклеген сиземли башладым. Алтын кеше иде ул. Таләпчән, әмма гадел. Хәзер ишеткәлим: минем хакта да шулай сөйлиләр.

Өстәвенә мин һөнәремне бик яратам. Туган якны өйрәнү өлкәсендә дә әдәбиятны, тел белемен кулланам. Берничә китабым да бар. Икесе әти-әниемә багышланган. Әтием гомере буена шофер булып эшләгән, сугыш ветераны, бүләкләре бар, без аларны кадерләп саклыйбыз. Әнием исә 8 сыйныфтан соң бухгалтерлар курсын тәмамлаган да шул юнәлеш буенча хезмәт куйган. Безнең нәселдә шундый закончалык бар: беркем дә сайлаган һөнәренә хыянәт итми. Үзем дә – шул рәттә.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Авыл язмалары

Марат КӘБИРОВ

Үзгәреш

Үрмәкчедән күрмәкче дигәнрәк нәрсә бөтен авылда да була торгандыр инде ул, бездә генә түгелдер. Декабрь урталары җиткәндәрәк бер авылдаш тәрәзәләренә челтәрләп гирлянда элеп куйган. Кечке урам буйлап атлаганда күз төште моңа. Матур инде шундый, төрле төсләргә кереп балкый, әле тиз-тиз генә, әле аз гына акрынаеп сүнеп-янып тора. Яңа елга да озак калмаган бит инде. Теге утлар белән бергә күңел дә җемелдәгән шикелле була, хисләр иләсләнә, иңнәргә канат үскәндәй тоела. Җыйнак кына йортның кечкенә тәрәзәләрендә балкыган бизәкле ут шулай җанга ямь өсти.

Моны күреп кайткач, без көн дә кечке урам буйлап әйләнеп килергә гадәтләнеп киттек. Рәхәт икән ул, яшьлекнең сөйгән ярың белән култыклашып йөргән мизгелләренә кире кайткандай тоеласың. Бүтән авылдашлар да шулай кич йөрергә чыга икән. Кайберләре скандинав таягына таянып чыга, кайберләре хәләл җефетен култыклап. Көндезләрен беркем дә узмаган урам кичкә шулай җанланып киткәндәй була. Үзеңне кешеләр арасындагы кебек итеп тоясың. Һәм, әлбәттә, теге бизәкле тәрәзә үзенә чакырып тора. Кешенең тәрәзәсе каршысына басып озак торып булмый бит инде. Шуңа без адымнарны акрынайтып кына узабыз, аз гына арырак киткәч борылабыз да шул тәрәзәдән күз алмыйча үтәбез, аннан тагын борылабыз… Шул рәвешле теге тәрәзә яныннан әллә ничә кат урыйбыз. Тәрәзәдәге бизәкләрдән ургылган нур күңелгә тулган шикелле була…

Болай кыланып тилереп йөрүчеләр бер без генә булмаганбыз бугай. Берничә көннән башка тәрәзәләрдә дә шундый ук гирляндалар пәйда булды. Башта бер, ике генә… аннан соң күбрәк… Ә азакка таба… бер авылдаш бөтен йортын шундый гирлянда белән төреп алган… Әкияттәге кебек булып тора инде… Күзләрнең явын алырлык кына түгел бу, әллә нинди менә… сүзләр белән генә аңлатырлык та түгел… Тирә якта ап-ак кар, зәңгәрсу караңгылык һәм төрле төсләргә кереп балкып утыручы йорт. Утлары да аның гади генә итеп сүнеп-янып кына тормый бит әле, биилар алар, әллә нинди өнсез моң хасил итеп биешәләр, ул моңны колак ишетмәсә дә, күзләр күрә бит инде, күзләрдән кереп күңелдә биешә башлый нурлардан яралган шул моң.

Рәхәт.

«Тиздән Яңа ел җитәчәк», – дип, күңел талпынып-талпынып куя. Җан җемелди Яңа елны көтеп. Әллә нинди, әйтеп аңлатып булмаслык якты тойгылар күңелдә. Кайчагында үзеңне дә әнә шул гирлянда утларына охшатып куясың. Без дә тормышның зәңгәрсу караңгылыгын матурларга тырышып, төрле төсләргә кереп җемелдәгән булабыз бит инде. Һәрберебезнең үз яктылыгы, үз төсе бар, кемнәрдер тиз-тиз елкылдый, кемнәрдер акрынрак… Нәтиҗәдә тормыш биюе хасил була. Галәмнәргә менеп карасаң, Җир шары да иң якты йолдызларның берәрсе шикелле ялык-йолык итеп торадыр әле. Әнә шул, безнең ялт-йолт килеп яшәү балкытадыр бит инде аны…

Яңа ел якынлашуга бөтен йортларда да әнә шундый гирляндалар пәйда булды. Бер кеше шәһәргә баргач очраткан да алып кайткан инде. Шуннан күреп кемдер сораган, кайдан алганын белгәч, беркемгә дә әйтеп тормыйча гына үзе дә алып кайтып куйган. Кайда сатылганын белгәч, икенче авылдаш та өен бизәргә булган. Шулай кызыксыну туган. Ә мондый тауарга ихтыяҗ барлыгын чамалагач, авылның бер сәүдәгә хирыс кешесе күмәртәләп алып кайткан да бөтен кешегә дә саткан. Без дә алдык. Эләргә мөмкин булган барлык урынга да гирлянда элеп чыктык…

Яңа елга авылның кеше яшәгән барлык йортлары балкып тора иде. Әле күпләре тәрәзәләрен, өен генә түгел, сарайларын, келәтләрен, капкаларын да шундый утлы бизәкләр белән әйләндереп алган. Кечке авыл урамында үзеңне әкият дөньясындагы кебек тоярлык булган. Соклангыч инде… Ничә тапкыр сөйләсәң дә, әйтеп бетерерлек түгел.

Яңа ел бәйрәме узды менә. Теге матур бизәкләр инде сирәкләнә төште. Авылда беренче булып бизәлгән тәрәзәдә әле һаман тора. Хәзер инде без аның яныннан сокланып узмыйбыз. Әллә ничә кабат урамыйбыз. Күңелдә дә әллә нинди якты тойгылар канатланып калмый. Киресенчә…

Әйе, нәкъ менә киресенчә хәзер. Элек бу йортның хуҗасы бик уңган булып тоела, сокланырга мәҗбүр итә иде. Хәзер аның тәрәзәсендәге җемелдәгечләр эчне генә пошыра, урынсыз һәм вакытсыз балкыган әрсезлек нурлары кебек күренә. Йорт хуҗалары да булдыксыз һәм зәвыксыз затлардыр сыман… Ә теге утлар һаман сүнә белми, һаман яналар, үчекләгән сыман кыланалар…

Югыйсә бер нәрсә дә үзгәрмәде бит инде. Тирә-якта шул ук апак карлар, зәңгәрсу караңгылык, шул караңгылыкны бизәргә тырышып җемелдәгән төрле төстәге утлар. Барысы да шул ук, элеккечә.

Һәм нәрсәдер бүтән…

Росреестрның Татарстандагы идарәсендә ведомство хезмәткәрләренең уңышлары билгеләп үтелде

Росреестрның Татарстандагы идарәсе җитәкчесе Азат Җәббаров, күчемсез милеккә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алу системасы оештырылуга 25 ел тулу уңаеннан, хезмәт бурычларын югары профессиональ дәрәҗәдә, намус белән үтәүләре һәм нәтиҗәле эшләүләре өчен 328 дәүләт теркәүчесенә Рәхмәт белдерде.

Дәүләт теркәүчесе вазыйфасы – ә аңа кадастр учетын алып бару һәм хокукларны теркәү вәкаләтләре йөкләнгән – чиктән тыш җаваплы вазыйфа, чөнки нәкъ менә ул, документларга хокукый экспертиза үткәреп, ахыргы карарны кабул итә.

«Һәр көн саен дәүләт теркәүчеләре тарафыннан 40–50шәр эш карала. Бик зур эш һәм шул ук вакытта бик зур җаваплылык бу. Росреестр системасында бер йодрыкка тупланып эшләвегез, уртак эшкә карата җаваплы мөнәсәбәтегез өчен сезгә рәхмәт белдерәм. Алга таба да югары нәтиҗәләргә ирешүегезне телим! Барлык эшләр һәм башлангычларыгызда уңышлар насыйп итсен!» – диде Азат Җәббаров.

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70. E-mail: vtreklama@mail.ru

Бергә җыелганда

Балалар һәм әти-әниләр өчен махсус сәхифә

Киңәш-табыш

ӘТИ-ӘНИ КОЛАГЫНА

1 Балагызның үзегез кебек яки сез теләгәнчә булуын көтмәгез. Аңа үзегез кебек булырга түгел, ә үзенчә булырга ярдәм итегез.
2 Балагызны ашыктырмагыз. Вакытны дөрес бүләргә өйрәтегез.
3 Һәрчак сүзегездә торыгыз, аны беркайчан да бозмагыз. Балага берәр нәрсәдә вәгъдә бирсәгез, аны үтәгез.
4 Балагызга карата гадел булыгыз, бу – аны гаделлеккә өйрәтүнең иң яхшы юлы.
5 Баланы үзе турында гына уйламыйча, башкалар турында кайгыртырга өйрәтегез. Чит кешенең дә кайгысын уртаклашырга, аның хисләрен аңларга, аңа ярдәм кулы сузарга өйрәнсен.
6 Үзегез ялгышкан очракта, баладан гафу үтенегез.
7 Балагызны «син булдырасың, синең бөтенесе дә килеп чыгачак» дигән сүзләр белән куәтләп торыгыз.
8 Баланы тыңлагыз һәм аның һәр сүзенә карата игътибарлы булыгыз.
9 Бала үзенең проблемаларын үзе чишәрлек итегез. Кайчагында, ул үзе сизмәслек итеп кенә, аңа ярдәм итегез.

КӘРИМӘ МОСТАЕВА:

«КУРАЙНЫҢ БӨТЕН ДӨНЬЯДА ЯҢГЫРАВЫН ТЕЛИМ»

Милли уен коралларында уйнаучы балалар сирәк, әмма алар бар. Шундый сәләтле балаларның берсе – Кәримә МОСТАЕВА. Курай, флейта, барабаннар. Кызчык уйный торган музыка коралларының берничәсе генә әле бу.

:: Курайда уйнау теләге ничек барлыкка килде?
– «Бала-сити» балалар бакчасына йөргәндә, бакча директоры Альбина Насыйрова миңа ансамбльдә уйнарга тәкъдим итте. Ул вакытта курай буенча укытучым «Риваять» төркеменең курайчы солисткасы Гәрәева Ләйсән Нургаязовна гастрольләрдә иде. Август аенда аның төркемендә шөгыльләнә башладым. Миннән соң бөтен төркемебез диярлек Ләйсән Нургаязовнаның дәресенә чиратка язылды. Курайда инде 6 ел, 3 ел флейтада, 2 ел барабаннарда уйныйм, «PRIMA» Яхиннар музыка студиясенә йөрим. «Казантип» дигән рок-группада да уйныйм, алар белән концертларда чыгыш ясыйм.

:: Нинди музыка коралында уйнарга җиңелрәк? Кайсы күбрәк ошый?
– Үзем уйный торган барлык музыка коралларын да яратам. Алар бөтенесе дә билгеле бер осталык таләп итә. Әйтик, барабанда уйнау өчен ритм хисе булу кирәк. Мин берничә ел скрипка белән дә шөгыльләнеп алдым. Ел ярым электрогитарада уйнадым. Уйныйсы килгән инструментлар күп, тик барысына да вакыт җитми. Атнага берничә мәртәбә курайга һәм барабанга йөрим. Минемчә, хәзер курайда уйнау яңадан модага керә башлады. Бу бик сөендерә. Чөнки бу – безнең милли традицияләр. Дәресләрне зарыгып көтеп алам. Кечкенә чакта әнине тыңламаган вакытта, ул миңа «курайга бүтән бармыйсың» дип әйтеп куркыта торган булган хәтта. Мин елаганмын *(көлә)*.

:: Курайчылар арасында кумирларың бармы?
– Кумирым – остазым Ләйсән Гәрәева. Мин аңа бик рәхмәтле.

:: Ә нинди көйләр башкарасың?
– Кечкенә чакта «Су буйлап», «Әнисә», «Туй» бию көйләрен башкара идем. Үзебезнең милли көйләрне, заманчаларны, башка халыкларныкын да уйныйм. Курай ул – бик уңайлы корал, барысына да көйләнә.

БЕЛЕШМӘ
- Кәримәгә – 11 яшь.
- Казанның 3 нче гимназиясендә 5 нче сыйныфта укый.
- 21 нче балалар музыка мәктәбендә шөгыльләнә, «Әллүки» курайчылар студиясенә йөри.
- Республикакүләм конкурслар лауреаты, Казан мэры стипендиаты.

:: Сәхнәдә үзеңне ничек хис итәсең? Дулкынланмыйсыңмы?
– Сәхнәгә чыгар алдыннан бераз борчылам, ә чыгыш ясый башлагач, дулкынлану хисе бөтенләй юкка чыга. Мин шундук музыкага чумам. 6 яшьтән конкурсларга йөри башладым. Республикада уза торган күп кенә чараларда катнашам. Шулай шомарып беттем инде. Узган елның маенда әниемнең туган районы Балтачта үземнең беренче концертым булды. Быел Казанда үткәрәсебез килә.

:: Музыка коралларында уйнаудан тыш, тагын нәрсәләр белән шөгыльләнәсең?
– Рәсем түгәрәгенә йөрим, төрле эшләнмәләр ясарга яратам. Энем белән картоннан йортлар төзибез. Гаилә белән Россия һәм Европа буйлап машинада сәяхәт итәргә яратабыз. Барлыгы 20 илдә булдым. Европа буенча бер ай сәяхәт иттек. Узган елны Грузия белән Төркияне әйләнеп кайттык. Сәяхәткә барганда мин үзем белән курайны да алам. Төрле җирләрдә чыгыш ясыйм. Кешеләргә бик ошый, алар кул чаба, тукталып тыңлап торалар. Курайның бөтен дөньяда яңгыравын телим.

:: Үзеңне киләчәктә кем итеп күрәсең?
– Киләчәктә үземне яхшы музыкант итеп күрәм. Россиянең атказанган артисты булу хыялы да бар. Музыка, курайда уйнау миңа зур бәхет китерә.

Бергәләп ясыйбыз

Иделия Бәдертдинова, 7 яшь, Актаныш

Бу – кызык!

ӘЙЛӘНӘ-ТИРӘ ДӨНЬЯ

Экстремаль шартларда исән калу турындагы китап авторлары раславынча, чүлдә сусыз калган кеше 1–2 тәүлек эчендә үлемгә дучар була.

Иң салкын температура 2013 елда Җир йөзенең иң салкын материгында – Антарктидада теркәлгән. Тикшеренүчеләр минус 91,2 градус күрсәткечен эләктереп кала алганнар.

Кеше кулына эләккән иң эре кар бөртегенең диаметры 38 см булган.

Кашалотлар үзләренең корбаннары артыннан 1–3 км тирәнлеккә кадәр төшә ала. Бу һава сулый торган хайваннар өчен рекорд булып тора.

Аякларында урнашкан бизләре аркасында, куян эзләреннән бик көчле ис килә, шуңа күрә алар йокыга киткәндә яисә үзләрен эзәрлекләүне сизгәндә, элмәкләр ясый-ясый, эзләрен чуалталар.

Китның борын тишекләре баш түбәсендә урнашкан, шуңа күрә ул су өслегендә һаваны чыгарганда, аның өстендә пар фонтаны барлыкка килә.

Башыңны эшләт!



Ребусны чишеп, халык әйтемен укыгыз.

Безгә язалар

УКЫТУЧЫМ

Узган ел мәктәпне тәмамлап, югары уку йортына керергә насыйп булды. Баштарак студент тормышын күз алдына да китерә алмый идем. Ничек итеп кешеләр белән аралашырга, ничек сүз башларга дип баш ваттым.

Тормыш өйрәтә икән ул. Әкренләп барысына да күнектем. Инде беренче сессияне ябабыз.

Укытучыларым бик ошый, үзем бер генә дәресне дә калдырмыйча укыдым. Укытучылар дигәннән, аларның арасыннан да иң якыны була икән. Без физкультура дәресләрен укыткан ир-ат мөгаллимне бөтен төркемебез белән бер күрүдә ошаттык. Буйга бик кечкенә, әмма үзе төш кенә ул! Ул чакта яшен дә белмибез, исем-фамилиясе дә истә калмады. Әмма бу укытучының дәресләрен дүрт күз белән көтә башладык. Башка вузда укучы танышларым, физкультура дәресеннән качып йөрибез, укырга бармыйбыз, дисәләр, без дәрескә ярты сәгать алдан йөри башладык. Безгә булган аталарча кайгыртуы да ошады. Без аның Алексей Бозин икәнен белдек. Әмма кемлеге, нинди спорт төрен яратканы, үткәне белән кызыксынмадык.

Шушы көннәрдә телевизордан тапшыру бара. Безнең Бозинны күрсәтәләр. Тын да алмыйча тапшыру карадык. Баксаң, безгә белем бирүче укытучыга 70 яшь икән. Шул мәлдә күз алдыннан аның мәтәлчек атулары килеп басты. Гәүдәсен җиңел йөртүенә исебез китте. Шушы яшьтә дә егетләрчә калып була икән.

Укытучым турында күпне белдем. Ул – грек-рим көрәше буенча атказанган мастер, СССР чемпионы, Европаның өченче дәрәҗә призеры һәм 1977 елда үткәрелгән Бөтендөнья универсиадасы призеры, Россиянең атказанган спорт мастеры. Ул спорт карьерасын армиядән кайткач кына башлый. 52 килограмм булса да, 100 килолы штанганы күтәрә. Йөз метр араны 12 секундта йөгереп килә.

– Грек-рим көрәше – спортның катлаулы төре. Монда җитди җәрәхәтләр алырга мөмкин. Мин һәрчак бу спорт төренең үземнеке икәнен тоеп тордым. Күп тапкыр Мәскәүгә дә чакырдылар, әмма туган ягымны ташлап китмәдем, – ди Анатолий Алексеевич.

Ул Мамадыш районының Кама Урман хуҗалыгы авылында туып-үсә. Язмыш аны Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясенә алып килә. Ул шунда эшли башлый.

Анатолий Бозин күптөрле чемпионатларда катнаша, җиңүләр яулый, дәрәҗәле урыннар ала. Үҗәт булуы, тырышлыгы аркасында аның исеме бөтен дөньяга танылa. Соңгы тапкыр көрәшүе 1983 елда була аның. Мәскәү спортчысы Виктор Савчукны 10:0 белән җиңеп, чемпион исемен ала. Шушы көрәштә умырткасына зыян килә. Анатолий Алексеевичка көрәшне ташларга туры килә. Шулай итеп ул Россия җыелма командасыннан да китеп бара.

Бүген Анатолий Бозин студентларга белем бирә. Аның дәресләрендә ял итәсең. Гәүдә языла, кайчак аңа карап, сикерә дә алмаганыбызга ачу килә. Яшен дә белгәч, укытучыга булган хөрмәтебез тагын да артты. Һәр балага җылы сүзен таба ул. Спорт түгәрәгенә йөрүчеләргә исә бар мөмкинлекләр тудыра. Хәтта кайчак студентларны тәмле чәй белән сыйлый. Киң күңелле, мәрхәмәтле, кешелекле укытучылар булганда, уку да рәхәт. Дәрескә йөрисе килеп тора.

Дилә ГЫЙЛЬМАНОВА,
КДВМАның I курс студенты

Әтием – герой

Җир йөзендә иң якын кешеләр – әти-әнидер. Әни үзенең назын бирсә, әти һәр яктан терәк булып тора. Әтиләрнең канат астында үзеңне көчле һәм иркен хис итәсең. Минем әтием дә – бик яхшы, олы җанлы, әйбәт кеше. Әтием минем өчен герой, чөнки ул Әфган сугышында катнашкан.

Әтием, Дәүләтшин Әхәт Рәфкать улы, Саба районы Түлешкә авылында 1963 елда туа. 1966 елны Арча районы Айван авылына күченеп кайталар. Балачактан әтием тыйнак, акыллы егет булып үскән. Төбәк-Чокырча сигезьеллык мәктәбендә һәм Арча 2 нче номерлы урта мәктәбендә белем алган. Шофер һөнәрен үзләштергән. 1981 елда армия сафларына алынган. Әфганстанның башкаласы Кабул шәһәрендә интернациональ бурычын намус белән үтәгән. Батырлыклары өчен орден-медальләр белән бүләкләнгән, грамота һәм рәхмәт хатлары бирелгән. 1989 елда туган авылына әйләнеп кайта. Төп һөнәре – умартачылык, аучылык белән дә шөгыльләнә.

Әтием үзенең армия тормышы турында сөйләргә яратмый. Мин кызыксына башласам, уйга талып, тынып кала, хәтта күзләре дымлана. Хәзерге көнгә кадәр яралы йөрәге төзәлмәгән. Әйе, аларның батырлыгына, кыюлыгына таң калырлык. Яшь-яшь килеш ут эченә барып кереп, хезмәтләрен намус белән башкарып, исән-сау әйләнеп кайттылар бит алар!

Аннан соң чирек гасыр үтсә дә, үлем белән күзгә-күз очрашкан егетләребез бүген дә төннәрен саташып уяна, тау-кыялар арасында мәңгелеккә ятып калган дусларын сагынып, әрнеп яшь түгәләр, үсеп килүче, солдат шинеле киячәк уллары, оныклары язмышын күзаллап борчылалар.

Ә бит адәм баласы күтәрә алмаслык баласын югалту ачысын кичергән гаиләләр күпме? Ходай сабырлык бирсен!

Әфган сугышы… Әфганстан… Күпме кешеләрнең кояшлы көннәрен, тыныч төннәрен урлаган, күпме кешеләргә кайгы китергән… Әтием сөйләвеннән мин армиядә көч, җитезлек, игътибар, корал белән идарә итү һәм катгый дисциплина кирәклеген аңладым. Әйе, армия көчле һәм куәтле булырга тиеш. Әмма берәү дә хезмәт итмәсә, армия бетәчәк һәм Россия теләсә кайсы, хәтта бик үк көчле булмаган дәүләт өчен дә җиңел табышка әвереләчәк. Армиядә хезмәт итү мәҗбүри түгел, дип санаучылар бу хакта уйлансын иде.

Хәзерге көндә Украина якларында барган сугышка да йөрәк әрни. Күпме яшь гомер киселә. Балалар ятим кала, аналар улларын югалта…

Без – тыныч тормыш балалары. Дөньябызның тыныч булуын, балаларның шат елмаю тавышын гына ишетергә телибез. Әниләребезнең, балаларның күз яшьләре җиребезгә таммасын иде. Әфганстан, Чечня фаҗигаләре башка кабатланмасын, бу сугышларда һәлак булган солдатларның ата-аналары күргән кайгылар башка беркемнең дә башына төшмәсен иде. Хәзерге вакытта хәрби хезмәттә булган абыйларга армия хезмәтен үтеп, исән-имин туган якларына әйләнеп кайтуларын теләп калам.

Әмир ДӘҮЛӘТШИН,
Арча җиденче номерлы
урта мәктәбенең 11 нче сыйныф укучысы

Сәхифәне Ләйсән САФИНА әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5322 данә
Гомуми тираж – 15277 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 217

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+